ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацына «укыту,» сүзеннән соң «халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм укыту» сүзләреннән соң «, халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җәмгыятьтә санитария-гигиена культурасын һәм гражданнарда сәламәт яшәү рәвешенә мотивация булдыру максатларында халыкны санитария-гигиена ягыннан агарту үткәрелә, ул, дөрес туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, сәламәт яшәү рәвешен булдыру, авыруларны профилактикалау, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен кирәкле белемнәрне, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүнең башка мәсьәләләре буенча белемнәрне тарату юлы белән, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, басма продукцияләрдән (белешмәләрдән, буклетлардан, плакатлардан һәм башкалардан), социаль рекламадан файдаланып, шулай ук оештырылган коллективларда чаралар, гражданнарга индивидуаль консультацияләр үткәргәндә гамәлгә ашырыла.

Халыкны санитария-гигиена ягыннан агартуны үткәрү тәртибе, шартлары һәм рәвешләре һәм аны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе мәгариф турындагы законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 февраль
№ 6-ТРЗ